| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БУИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.12.2018 Буа шәһәре № 397/ИК-п

2019 елга Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмасы эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2013 елның 30 декабрендәге 1096 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2019 ел өчен кушымтада бирелгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар;

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны карап торган һәм караган өчен ата-аналар түләве күләме.

2. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Финанс-бюджет палатасында түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

әлеге карарның 1 пункты белән расланган мәктәпкәчә мәгариф оешмаларын финанслау нормативлары нигезендә мәктәпкәчә мәгариф оешмаларын финанслау.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль мәсьәләләр буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Л.Н. Садретдиновага йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Камартдинов

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
2018 елның 18 декабрендәге 397/ИК-п номерлы
карары белән расланды

## Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә

## НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

1. Гади балалар бакчаларында тәрбияләнүчеләрне азык-төлек продуктларына чыгымнарны исәпкә алмыйча карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар

| Мәктәпкәчә мәгариф оешмасының атнага эш көннәре саны | Мәктәпкәчә мәгариф оешмасының атнага эш сәгатьләре саны | Мәктәпкәчә белем бирү оешмасының территориаль дислокациясе | Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар, сум / ел/ тәрбияләнүче | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | бер яшьтәге төркемнәр | | | төрле яшьтәге төркемнәр | | | Гаилә балалар бакчалары төркемнәре |
| | | | 2 айдан 1 яшькәчә | 1 яшьтән 3 яшькә кадәр | 3 яшьтән 7 яшькәчә | от 2 месяцев до 3 лет | три возраста от 3 до 7 лет | два возраста от 3 до 7 лет | |
| 5 эш көне | 3 | Шәһәр җирлеге | 12717 | 10732 | 8748 | 14701 | 12717 | 8748 | |
| | | Авыл җирлеге | 12945 | 10929 | 8913 | 14960 | 12945 | 8913 | |
| | 4 | Шәһәр җирлеге | 17019 | 13051 | 11066 | 20491 | 17019 | 9579 | |
| | | Авыл җирлеге | 17344 | 13313 | 11297 | 20842 | 17344 | | |
| | 5 | Шәһәр җирлеге | 17850 | 13881 | 11400 | 21818 | 17850 | | |
| | | Авыл җирлеге | 18240 | 14209 | 11665 | 22272 | 18240 | | |
| | 6 | Шәһәр җирлеге | 18680 | 14712 | 12231 | 22649 | 18680 | | |
| | | Авыл җирлеге | 19136 | 15105 | 12561 | 23168 | 19136 | | |
| | 7 | Шәһәр җирлеге | 28639 | 23550 | 21500 | 32707 | 28639 | | |
| | | Авыл җирлеге | 28953 | 23739 | 21657 | 33084 | 28953 | | |
| | 9 | Шәһәр җирлеге | 37567 | 30494 | 26459 | 43619 | 37567 | | |
| | | Авыл җирлеге | 38275 | 31036 | 26934 | 44428 | 38275 | | |
| | 10,5 | Шәһәр җирлеге | 41536 | 31487 | 26956 | 47588 | 41536 | | |
| | | Авыл җирлеге | 42307 | 32092 | 27462 | 48459 | 42307 | | |